


Мордовия республикасы мәгариф министрлыгы карамагында сәләтле балалар очен 16нчы тапкыр «Яшә, туган тел!» этномәдәни регионара ял лагере эшли. Балалар Краснослабодск районындагы «Сивинь» җәйге лагерь базасында ял итәләр.
Мордовия мәгариф Министрлыгы баш белгече Надежда Васильевна Салмова белән аралашканда: «Рус, мордва һәм татар халыкынын телен ойрәнv теләге булдыру, тарихына кызыксыну уяту, халыкларнын милли-мәдәни vзенчәлекләрен саклау, дуслыкны ныгыту, сәламәт яшәv нигезләрен формалаштыру – балалар очен оештырылган «Яшә, туган тел!» дигән этник лагерьнен максаты. Быел бу лагерьдә Мордовиядән, Татарстаннан, Башкортстаннан, Владимир, Пенза, Ульян, Мәскәv олкәләреннән туган теле, әдәбияты олимпиадаларында җинvчеләр, туган теле һәм мәдәнияты буенча торле конкурсларда, фольклор торкемнәрендә катнашкан балалар ял итә. Алар белән бергә лагерьнын этномәдәни программасында Мордовия республикасы югары квалификацияле педагоглары һәм чит регион балаларын алып килгән укытучылар да актив катнаша.
Гадәт буенча алар очен, тел vзенчәлекләрен исәпкә алып, оч отряд оештырылды: мукшы, әрзә, татар милләтле балалардан торган. «Яшә, туган тел!» җәйге этномәдәни балалар лагерендә 20 кон дәвамында торле мероприятияләр уздырыла, кин ял итv программалары да каралган. Татар группасы белән дvртенче ел беррәттән унышлы Ләмберә районы Черемиш гомуми топ мәктәбенен югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фазия Фәрит кызы Боярова эшли».
Быел татар милләтле балаларыбыздан Ләмберә районы Черемиш авылыннан - Тимерлан Карабанов, Диана Зинченко, Дарина Маринова, Динар Чураков, Ләмберәдән - Азамат Бояров, Рузаевка районы Татар Пешләсеннән - Алина Биксаляева белән Сабина Касимова бу ял лагерена килделәр.



- Балалар лагерьда булу белән бик канәгать. Кvнелсезләнергә вакыт юк, ял программасы тыгыз; алар бер-берсе белән аралашалар, бергәләп ял вакытларын vткәрәләр, торле чараларда һәм мастер-классларда рәхәтләнеп катнашалар. Мәсәлән, мин vткәргән мастер-классларда татарлар гына тvгел, мордва һәм рус  милләтле балалар да татар жырларын жырлыйлар, биюләрен биилэр. Тагы шуны әйтеп китәсем килә: биредә милли билге буенча бvленеш юк, - дип сойли Фазия Фәрит кызы Боярова. - Шулай ук мордва биюләрен татарларыбыз рәхәтләнеп бии. Ин моһиме, балалар барысына да янәшәдә яшәvче халыкларнын теле, гореф-гадәтләре белән кызыксыналар.

Программабыз тыгыз. Үткән атнада Наровчатта экскурсиядә булдык, уникенче июльдә Мордовиянен атказанган язучылары белән очраштык, барлык балалар белән бергәләшеп «Сабантуй» vткәрергә әзерләнәбез, - дип эш планы белән таныштырды Фәрит кызы Фазия.
Алда әле балаларнын тагын берничә кон актив таныпбелv ялы бар. Алар кvтәренке кәеф белән ниндидер яна һәм кызыклы нәрсәләр белән танышу очен һәр конне котәләр. «Сивинь»дә, сәләтле балалар очен оештырылган этномәдәни лагерендә, ял итvчеләр туган якларын, анын тарихын тирәнтен vзләштереп, ойләренә сәламәтлекләрен ныгытып, мәдәни баеп, кvп кенә дуслар булдырып кайтачаклар.

**Наилә Насырова**